**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 85пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 августындагы 203 пи номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.03.2015 ел, №1389/15 боерыгы белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 29.04.2016 ел, №ПУ – 832/16 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 5 августындагы 203 П номерлы карары (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 79пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары)төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм күчерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.14.Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларга социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда башкарыла. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына киртәләрсез үтеп керү мөмкинлеге, шул исәптән объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

1.2. 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.15.Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бина җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, интернет челтәрендә, «Мәгариф бүлеге» МКУ рәсми сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү | "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу; законда каралган инвалидлар өчен уңайлы шартлар булу. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты характерлана: документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү; муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү; муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар кылган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы. | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин